РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«31» июль 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 177

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гәвами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2017 елның 29 декабрендә чыккан 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының 2008 елның 23 маенда чыккан 138 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гәвами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе Нигезләмәсе турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гәвами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гәвами тыңлаулар үткәрүнең районның генераль планы проекты буенча үткәрү үзенчәлекләре

9.1. Генераль план проекты, аңа үзгәрешләр кертү карары проекты расланганга кадәр өч ай алдан рәсми бастырылырга һәм районның Интернеттагы рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш. Генераль план проекты беренче гәвами тыңлаулар үткәрелгәннән соң бер ай эчендә Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән күләмдә мәгълүматлар бастырырга тиеш.

9.2. Муниципаль район Башлыгы генераль план проекты, аңа үзгәрешләр кертү карары проекты буенча гәвами тыңлаулар үткәрелгәннән соң бер ай эчендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча гәвами тыдлаулар үткәрү турында карар кабул итә һәм аның бастырылуын тәэмин итә.

9.3. Гәвами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аның мәгълүматый материалларын рәсми сайтта бастыру һәм рәсми сайтта экспозицияләр ачу яки шундый проект экспозицияләре ачу;

9.4. Җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәргәндә әлеге җәмәгать фикер алышуларында яки гәвами тыңлауларда катнашучыларны торак пункт территориясендә тигез катнашу хокукын тәэмин итү максатында кисәкләргә бүленергә мөмкин.

9.5. Гәвами тыңлаулар муниципаль районның һәр торак пунктында үткәрелә. Генераль планга үзгәрешләр керткәндә гәвами тыңлаулар бу үзгәрешләр территориясенә кагыла торган торак пункларда һәм бу торак пунктлар белән чиктәш торак пунктларда үткәрелә.

9.6. Әлеге проектның 4 өлешенең 2 пункты һәм 5өлешенең 2 пункты нигезендә, урнаштыру чорында әлеге проектка кагыла торган тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертә ала:

1) рәсми сайт яки системалар аркылы (җәмәгать фикер алышулары үткәргән очракта);

2) гәвами тыңлауларда катнашучыларның җыелышы яки җыелышлары үткәрелгәндә язмача яки телдән (гәвами тыңлаулар үткәргән очракта);

3) җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар оештыручы адресына язма формада;

4) җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язып.

9.7. Җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә хәбәр итү моментыннан җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар нәтиҗәсен бастырып чыгаруга кадәр, муниципаль берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлек вәкаләтле органы норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан азрак, өч айдан озаграк була алмый.

9.8. Генераль планга торак пунктлары чикләрен төзелеш яки рекреацион мәгънәдә үзгәртү белән бәйле үзгәрешләр җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәрмичә генә гамәлгә ашырыла.

9.9. Муниципаль район Башлыгы гәвами тыңлаулар нәтиҗәләре турында исәпкә алып карар кабул итә:

1) генераль план проекты белән килешү һәм аны муниципаль район Советына юллау турында;

2) генераль план проектын кире кагу һәм эшләп бетерүгә җибәрү турында»;

11пунктның 11.4. подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.4. Җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә хәбәр итү моментыннан җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар нәтиҗәсен бастырып чыгаруга кадәр, муниципаль берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлек вәкаләтле органы норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан азрак, өч айдан озаграк була алмый»;

12 пунктның 12.2. подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.2. Җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәрүне оештыручы җир кишәрлегенә хокукы булганнарга шартлы рәвештә куллану төренә рөхсәт турында әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган капиталь төзелеш объекты хуҗаларына кагылышлы карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары яки гәвами тыңлаулар үткәрү турында хәбәрләрне юллый. Күрсәтелгән хәбәрләр кызыксынган заттан шартлар рөхсәт ителгән куллану төрен куллануга рөхсәт сорап гариза кергәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча юллана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтка урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырылган көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Башлыгы,
Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин